СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №152 (7451) | 22 декабрь, 1992 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Смотрга йомгак ясалды

Гадәт буенча һәр елны ноябрь ахырында район колхоз-совхозларында техниканы иң яхшы саклауга кую буенча үткәрелгән смотр-конкурска йомгак ясала. **Йомгак вакытында машина-трактор паркына техник хезмәт күрсәтү, механизаторлар хезмәте өчен уңайлыклы шартлар тудыруга да зур әһәмият бирелә.**

Быел да махсус комиссия хуҗалыкларның машина-трактор паркларын җентекләп карап, техниканың сакланышы, эш шартлары тудыру ягыннан үз бәясен куйды. Карау барышында Синдряков исемендәге, «Ленинский путь», «Таң», «Игенче», «Заветы Ильича», «Россия», Мичурин исемендәге колхозлар, «Сөлчә», «Мамык», «Төрнәс» совхозларында техниканы кышкы саклауга үзвакытында һәм сыйфатлы итеп куюлары мәгълүм булды. Биредә ремонт мастерскойлары, гаражлар, техник хезмәт пунктларының әзерлеге дә югары бәяләнде. Әлеге хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы машиналарын үзвакытында һәм сыйфатлы ремонтлау өчен механизаторларга мораль һәм материаль стимул чаралары һәрьяклап каралган, баш агрономнар җитәкчелегендә ремонтланган машиналарны кабул итү буенча комиссия төзелгән иде.

Смотр-конкурсны үткәрү комиссиясе, аны үткәрү шартлары нигезендә башкарылган эшләрне һәрьяклап бәяләгәннән соң, җиңүче дип Синдряков исемендәге колхозны (колхоз рәисе С. И. Белогубов, баш инженер К. С. Фәйзуллин) тапты. Икенче урынга «Ленинский путь» колхозы (колхоз рәисе И. Н. Мөхәммәтов, баш инженер М. В. Михеев), өченчегә «Сөлчә» совхозы чыкты (совхоз директоры Р. Г. Шәйдуллин, баш инженеры Г. М. Шәрәпов). «Таң» һәм «Заветы Ильича» колхозларында да (баш инженерлары И. Н. Әхмәтшин, С. Н. Жлудников) техниканы саклауга куюга җитди караганнар.

Смотр-конкурс шартлары нигезендә беренче өч урынны алган хуҗалыкларның җитәкчеләре, баш инженерлары, трактор бригадасы бригадирлары өч—бер оклад күләмендә премия белән бүләкләнәчәкләр.

Шулай итеп, конкурс үз җиңүчеләрен билгеләде. Киләчәктә смотр-конкурс шартларын билгеләгәндә техниканы кую срогы һәм сыйфаты, һәр механизаторның аерым хезмәте исәпкә алыначак, шулай ук мастеркөйләүче җитәкчелегендә машина-трактор паркына техник хезмәт күрсәтү мәсьәләләре дә күз уңында торачак. Шулай итеп, яңа конкурска кадәр!

**Р. САТДАРОВ,**
«Гостехнадзор» инспекциясе начальнигы.

## Нефтьчеләр тотрыклы эшли

Базар экономикасына күчү «Норлатнефть» нефть һәм газ табучылары өчен дә эшне күпкә катлауландырды. Производствоны тәэмин итү өчен торбалар һәм башка төр җиһазлар табу, кайтару кыенлыклары өстенә финанс мәсьәләләре дә өстәлде. Нефтьчеләр алдында бурычлылар вакытында аны түли алмаганга бар җиһазларны сатып алу да күпкә кыенлаша.

Катлаулы шартларда эшләсәләр дә нефть чыгаручылар стабильлекне, тотрыклылыкны саклыйлар, җитештерүне үстерә баруга ирешәләр. Мисал өчен идарә 1991 ел дәвамында 1130 мең тонна «кара алтын» чыгарган булса, быел ул дәрәҗәне 11 айда үтеп китте. 1150 мең тонна җир асты хәзинәсен суыртты, планны 103,3 процент итеп үтәп чыкты. Планнан тыш 36,7 мең тонна нефть чыгарылды.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**



## Уңган механизатор

«Уңган механизаторларыбызның берсе ул, тырыш, эшчән»,—ди Николай Федорович Осипов турында «Комбайн» колхозы председателе Ә. С. Шәрәфетдинов. Хак сүзләр. Николай Федорович менә ничә елдан бирле инде хуҗалыкта механизатор булып эшли. Нинди генә техникада эшләргә туры килми аңа. Соңгы елларда Осипов Т-150 тракторын йөртә. Язгы, җәйге, көзге кыр эшләре беркайчан да аңардан башка узмый. Ул исә һичкайчан эштән баш тартмый, заданиесен һәрвакыт 100—130 процентка үтәп килә, колхоз механизаторлары арасында алдынгылыкны бирми.

Гомумән, нинди генә эшкә алынса да, аны намусы кушканча башкара.

Рәсемдә: «Комбайн» колхозы механизаторы Н. Ф. Осипов.

С. Хәйруллина фотосы.

● *Юбилейга интервью*

# Тынгысыз хезмәттә

**РСФСР Халык комиссарлары Советы 1922 елның 22 декабрендә үзенең «Дәүләт саклык кассалары турындагы положение»сен раслады һәм бу дата шуннан соң дәүләт саклык-банк системасы төзелү көне буларак билгеләп үтелә башлады.**

**Сезнең игътибарга әлеге бәйрәм алдыннан Октябрь саклык банкы бүлекчәсе управляющие урынбасары Ә. У. АБДУЛЛИН белән булган әңгәмәнең язмасын тәкъдим итәбез.**

**КОРР. Әнвәр Усманович! Быел сезнең служба үзенең түгәрәк датасын билгеләп үтә икән.**

—Әйе, рәсми рәвештә карасак, без быел 70 еллыгыбызны бәйрәм итәбез. Хәер, әгәр төгәлрәк әйтсәк, Россиядә беренче саклык кассаларына нигез салынганга гасыр ярымнан да артыграк вакыт үткән. Әле 1841 елда ук патша Николай I саклык учреждениеләре булдыруны күздә тоткан указ бастырып чыгарган һәм 1842 елның язында инде Петербургта һәм Мәскәүдә беренче кассалар ачылган да. Ул гына да түгел, Екатерина II заманында ук әле саклык казналары дип аталган казна банклары ачылган. Бу банклар барлык теләүчеләрдән вкладлар кабул итәләр һәм ссудалар бирәләр.

**КОРР. Шулай итеп, Екатерина чорындагы саклык казналары бүгенге саклык банкларының башлангычы булып чыгамени инде? Бу вакыт аралыгында аларның эшчәнлек сферасы ни рәвешле үзгәргән соң?**

—Әлбәттә, саклык-банк системасы үзенең оешу һәм үсү елларында җитди үзгәрешләр кичерде. Әмма аның асылы: акча средстволарын халыктан вкладлар буларак кабул итү һәм кредит хезмәте күрсәтү (озак вакытка һәм кыска вакытка ссудалар бирү) элеккечә калды.

Моннан тыш әле коммуналь хезмәтләргә түләүләр, барлык вакытлы финанс операцияләре (категория, заем һәм менә соңгы факт—ваучерлар бирү кебек эшләр) безнең ведомство аша үтә.

**КОРР. Әйе, ваучерлар, чынлап та, сезгә күп мәшәкать тудырдылар.**

—Без әлеге ваучерлар белән генә шөгыльләнсәк икән? Хәзерге вакытта безгә клиентлар белән акчасы кулдан түләнми торган исәп-хисап эшләре дә алып барырга туры килә. Аерым категория эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең касса аша саклык кенәгәсенә күчерелә торган хезмәт хакы гына да һәр көнне 10297 мең сумга якын күләм тәшкил итә.

Ә бит әле моңа колхозчыларның акча керемнәре дә (1179 мең сумнан артык), авыл хуҗалыгы продукциясе өчен, пенсия һәм башка түләүләр буенча яңабаштан исәп-хисап ясауларны да өстәргә кирәк. Күргәнегезчә, эш күләме җитәрлек, хәтта әле күп тә. Агымдагы елның 11 аенда саклык банкы тарафыннан 10508 мең сум күләмендә табыш алынды. Бу чорга вкладлар үсеше 51911 мең сум тәшкил итте.

**КОРР. Хезмәткәрләр турында сүз чыккан икән, аны төгәлрәк итсәк иде. Миңа калса, сездә телгә алып мактарлык кешеләр бар?**

—Һичсүзсез. Башка производстводагы кебек бездә дә алар бар. Саклык банкы бүлеге 34 подразделениене берләштерә. Шәһәрдә өчәү—калганнары авылларда. Эш җитәрлек. Шуңа да шимбә һәм якшәмбе көннәрендә дә эшләргә туры килә. Коллективны нигездә хатын-кызлар тәшкил итә. Кагыйдә буларак, хатын-кыз эшләгән җирдә һәрчак тәртип. Егоркино авылыннан Зинаида Филимоновна Сергееваны, Төрнәстән Хәлисә Әхмәт кызы Ишмөхәммәтованы гына алыйк. Алар намус кушканча эшлиләр, беркайчан телгә тидерерлек түгел.

Тикшерү контроле бүлеге начальнигы Вера Лаврентьевна Мокина, шул ук бүлек бухгалтеры Исламия Хәсән кызы Усманова, операция бүлеге мөдире Светлана Федоровна Давыдова, контролер Гөлфия тулаш Хисмәтуллина һәртөрле мактауга лаеклылар. Мондый исемлекне дәвам итәргә дә булыр иде. 70 еллыгыбызда сотрудникларның Татарстан банкының Мактау грамотасы белән бүләкләнүләре гаҗәп тә түгел. Мондый бүләккә безнең системада 16 ел эшләгән Сәрия Минсәлим кызы Летфуллина, Елаур авылыннан контролер Людмила Васильевна Дмитриева лаек булдылар.

**КОРР. Сезнең сүзләргә караганда саклык банкында чыннан да хезмәт алдынгылары күп икән. Тик тагын сезнең эшчәнлеккә кайтыйк. Соңгы вакытта илдәге инфляция коточкыч зурлыкка җитте, клиентларыгызның вкладларын саклау гарантиясе бармы?**

—Нәрсә дип җавап бирергә инде? Үзегез уйлап карагыз: срочный вкладларга 1991 елда калган вкладлар буенча еллык 9 процент күләмендә өстәп бирелә һәм 1992 елның 1 гыйнвареннан августка кадәр 25 процент итеп өстәп язу бара, ә августтан алып ел азагына кадәр бу күләм 50 процент итеп алына. Компенсация вкладлары буенча чагыштырмача 3 процент.

**КОРР. Мондый информация вкладчыларыгызны бераз тынычландырыр, аларның сафын арттырыр дип уйлыйбыз.**

—Моңа сөенер генә идек.

**КОРР. Без сезгә кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт белдерәбез һәм саклык банкы хезмәткәрләрен профессиональ бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Эшегездә уңышлар, сезгә.**

